РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ГЛАВА
МЕЩЕРЯКОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАРЛЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 08 » июнь 2023 ел № 4

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Карлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең чикләрен үзгәртү турында» 2023елның 30 маендагы 6-46 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карарына ярашлы рәвештә, Карлы авыл җирлегендә яшәүчеләрнең «Карлы авыл җирлеге» берәмлеге чикләре турындагы проектны гавами тыңлаулар үткәрү юлы белән фикер алышуда катнашу хокукын үтәү максатыннан

**КАРАР БИРӘМ:**

1.Беркетелгән карта - схема нигезендә (кушымта), Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Карлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге чикләрен үзгәртү мәсьәләсе буенча гавами тыңлаулар үткәрүне 2023 елның « 04 » июленә 11.00 сәгатьтә ТР, Буа районы, Карлы авылы, Татарстан урамы, 66 йорт адресы буенча ТР Буа муниципаль районы Карлы авыл җирлегенең Карлы авыл мәдәният йортында уздырырга дип билгеләргә.

2.Гавами тыңлауларда карала торган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2023 елның « 03 » июленә кадәр ТР, Буа районы, Карлы авылы, М.Җәлил урамы, 107 йорт адресы буенча, Буа муниципаль районы Карлы авыл җирлеге башкарма комитетында +7(84374) 40-7-94телефоны буенча кабул ителә.


3.Әлеге карар Карлы авыл җирлегендә ТР, Буа районы, Карлы авылы, М.Җәлил урамы, 107 йорт адресы буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан ителергә тиеш.

4. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ рәсми рәвештә бастырылган көннән башлап законлы көченә керә, шулай ук «Буа шәһәре» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

ТР Буа муниципаль районы Карлы
авыл җирлеге башлыгы Д.Х. Абдрахманов

ТР Буа муниципаль районы Карлы авыл җирлегенең
2023 елның 08 июнендәге 4 номерлы карарына
кушымта




**КАРТА(ПЛАН)**

**Мещеряковское сельское поселение**

(наименование объекта землеустройства)

**План границ объекта землеустройства**




**Масштаб 1 : 3000**

Используемые условные знаки и обозначения:

- характерная точка границы
- граница объекта землеустройства
- граница сельского поселения
- граница кадастрового квартала
- граница населённого пункта
- земельный участок, кадастровый номер
- подпись кадастрового квартала

Подпись кадастрового инженера ____ А.Р. [illegible]

Дата 27.04.2023

Место для оттиска печати лица, составившего карту (план) объекта землеустройства


**КАРТА(ПЛАН)**

**Мещеряковское сельское поселение**

(наименование объекта землеустройства)

**План границ объекта землеустройства**

**Выноска 2**




Масштаб 1 : 5000

Используемые условные знаки и обозначения:

- характерная точка границы
- граница объекта землеустройства
- граница сельского поселения
- граница кадастрового квартала
- граница населённого пункта
- земельный участок, кадастровый номер
- подпись кадастрового квартала

Подпись кадастрового инженера ____ /А.Р. [illegible]/

Дата 27.04.2023

Место для оттиска печати лица, составившего карту (план) объекта землеустройства